Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Кузайкино авыл Советы

КАРАРЫ

03 март 2020 ел № 113

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл Советының 2019 елның 23 октябреннәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл Советы җирлегенә керүче торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә хакында»гы 99 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясын гамәлгә ашыру максатларында

Кузайкино авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл Советының 2019 елның 23 октябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә хакында»гы 99 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5. пунктта «(2 нче кушымта)» сүзләрен «(үзара салым мисалында 2 нче кушымта үрнәге)» сүзләренә алмаштырырга, «(3 нче кушымта)» сүзләрен «(үзара салым мисалында 3 нче кушымта үрнәге)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.9.2. пунктында пунктында «(5, 6 нчы кушымталар)» сүзләрен «(үзара салым мисалында 5 нче, 6 нчы кушымта үрнәкләре)» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3.1 пунктының беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Җыенга килгән гражданнар җыенны оештыручы тарафыннан теркәлә һәм торак пунктта яшәүчеләр һәм җыенда катнашырга хокуклы затлар исемлеге белән чагыштырыла»

1.4. 3.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Исемлектә төгәлсезлекләр барлыгы ачыкланган очракта сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүче граждан шәхесен раслый торган документлар нигезендә җыенда катнаша ала»;

1.5. 3.8. пунктында «(7 нче кушымта)» сүзләрен «(үзара салым мисалында 7 нче кушымта үрнәге)» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 3.17. пунктында җәя эчендәге (14 нче беркетмә) сүзләрен (14 нче кушымта) сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 3.18 пунктта «җирлек башлыгы тарафыннан имзалана торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 4.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль норматив хокукый актлар булып тора, гражданнар җыенында рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.»

1.9. 4.5. пунктында «(үзара салым мисалында 15 нче кушымта үрнәге)» сүзләрен өстәргә;

1.10. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл Советының 2019 елның 23 октябрендәге 99 номерлы карарына кушымтаны әлеге карарга 15 нче кушымта белән тулыландырырга.

1.11. Нигезләмәгә кушымталарда «Иванова Светлана Ивановна - ФАП мөдире», «Иванов Иван Ивановичны», «Петрова Полина Петровнаны» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Кузайкино авылы, Совет урамы, 26 нче йорт авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кузайкино авыл
җирлеге башлыгы в.б. Е.В. Трифонов

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Кузайкино
авыл Советының 2020 елның
03 мартындагы 99 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы___________ авыл җирлегенең ______________ торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

__________ 20__ ел №........

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 20____елның "____"___________ ___ сәгать 00 минутта, 20____елның "____"___________ ____ сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сораулар буенча ---------------------------------------------------------------------------------- ------------------------------------------- гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә ____ кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны ____ кеше, бу ___% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның _____ "РИЗА" позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның _____ "КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы __________ авыл җирлегенең ________________ торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы_______ авыл җирлегенең ________________ авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын _____ елда_____сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:_______________________________________________.

4. Әлеге карарны______________________ территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты "Интернет" челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче